СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 13-15 от « 11 » августа 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы, 2022 елның 23 мартындагы 11-13 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасын 2022 елның 24 мартында 15-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 15.10.2015 ел, 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (12.11.2016 елгы 3-12 номерлы, 12.05.2017 елгы 8-16 номерлы, 26.07.2017 елгы 4-18 номерлы, 13.11.2017 елгы 4-19 номерлы, 29.06.2018 елгы 10-27 номерлы, 03.09.2018 елгы 8-28 номерлы, 19.11.2018 11-29 номерлы, 28.03.2019 елгы 8-32 номерлы, 23.07.2019 елгы 17-34 номерлы, 30.06.2020 елгы 12-39 номерлы, 10.06.2021 елгы 8-7 номерлы, 12.11.2021 елгы 13-9 номерлы, 23.03.2022 елгы 11-13 номерлы кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 26.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль районы финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүне үткәрү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла».

000084

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының (mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов